**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 10 декабрендәге 5098 номерлы карары**

**Казан шәһәре зиратларын карап тотуга**
**финанс чыгымнары нормативларын раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Баш санитар табибының 2021 елның 21 гыйнварындагы 3 номерлы «“Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчә торган суга һәм халыкны эчә торган су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак биналарга, җитештерү һәм җәмәгать биналарыннан файдалануга, санитар-эпидемиягә каршы (профилактика) чараларны оештыруга һәм үткәрүгә карата санитар-эпидемиологик таләпләр” 2.1.3684-21 номерлы санитария кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында»гы карары һәм Казан шәһәре Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы «Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Түбәндәге эш төрләре буенча Казан шәһәре зиратларын карап тотуга финанс чыгымнары нормативларын расларга һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә:

- чүпне контейнерларга кадәр кул белән чыгару – 1 куб м өчен 414,63 сум;
- чүпне механикалаштырылган ысул белән (кечкенә төягеч техника ярдәмендә) чыгару – 1 куб м өчен 464,62 сум;
- каты өслекле аллеяларны кул белән җыештыру – 1 кв.м өчен 6,08 сум;
- каты өслекле аллеяларны механикалаштырылган ысул белән җыештыру – 1 кв.м өчен 0,31 сум;
- карны кул белән җыештыру – 1 кв.м өчен 2,96 сум;

- карны механикалаштырылган ысул белән җыештыру – 1 кв.м өчен 0,30 сум;

- үлән чабу – 1 кв.м өчен 4,89 сум;

- үләнне механикалаштырылган ысул белән чабу – 1 кв.м өчен 0,35 сум.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының ритуаль хезмәтләрне оештыру идарәсенә (М.Ә.Ишкин) җирләү урыннарын карап тотуны һәм зиратлар территорияләрен системалы рәвештә җыештыруны тәэмин итәргә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 17 ноябрендәге 3577 номерлы «Казан шәһәре зиратларын карап тотуга финанс чыгымнары нормативларын раслау турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. 3 пункттан тыш, әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның 3 пункты 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә керә дип билгеләргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**